КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 август г.Казань № 697

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү үткәрү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 25 март, 171 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү үткәрү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 25 март, 171 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.1 пунктта:

«г» пунктчасында «һәм Килешү» сүзләрен төшереп калдырырга;

«д» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

3.5 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин